# Мин әтиемнең кызы

1) Мин әти белән бергә
Бик яратам уйнарга,
Тыпыр-тыпыр биергә,
Төрле жырлар жырларга

Кушымта:
Кайда булсак та
Анын белән гел кызык,
Гел әти белән бергә
Мин әтиемнең кызы

2) Әти эштән кайтуга
Өебезгә нур тула,
Аның белән төрле-төрле
Уеннар уйнап була

3) Качышлый уйнаганда
Әти мине табалмый,
Шыпырт кына утырам,
Кымшанырга ярамый